# Измайлова Зөлфия Фатыйх кызы



Белеме югары. 1967 елда Алабуга дәүләт педагогия институтының филология факультетын тәмамлый. 1967-1996 елга кадәр Мөслим урта мәктәбендә (1987 елдан Мөслим лицеенда) рус телен һәм әдәбиятын укыта.

Үз эшен бик яратып, намус белән башкара. Ата-аналар белән тыгыз бәйләнештә торып, балаларга яхшы тәрбия бирергә тырышкан. Зөлфия Фатыйх кызы “Россия Федерациясенең мәгариф отличнигы” исеменә лаек, хезмәт ветераны.

Укыткан укучылары арасында күренекле шәхесләр бик күп: укытучылар, табиблар, эшкуарлар.

Татарстан Республикасының Атказанган юристы, юридик фәннәр докторы Флүр Баһаутдинов, Мөҗәһит Әхмәтҗановның «Кыңгыраулы мәктәп еллары» китабында үзенең укытучылары турындагы истәлекләрендә болай ди: «Иске Вәрәш башлангыч мәктәбеннән Мөслим урта мәктәбенә килгәндә урысча бер сүз дә белми идем диярлек. Зөлфия Фатых кызы Измайлованың өйрәтүе нәтиҗәсендә мәктәпне бетергәндә рус телен рус балаларына караганда да яхшырак белә башладым. Гомер буе рус телен үз югарылыгында белү миңа ярдәм итеп килде: университетта яхшы укыдым, хокук органнарында да, дәүләт эшендә дә уңышлы хезмәт иттем»